БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«_17_» __04___ 2020 г. № _151_

**2019 - 2023 елларга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясындагы 1 өлеше нигезендә һәм «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты **карар бирә:**

1. 2019 елның 13 мартындагы 130 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының карары белән расланган 2019 - 2023 елларга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Исемдә һәм алга таба текст буенча «2019-2023» саннарын «2019-2024» санына алмаштырырга;

1.2. Муниципаль программа Паспортының «Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Барлыгы-агымдагы финанслау 2500 мең сум, шул исәптән:

- җирле бюджет - 2500 мең сум (2020 ел - 500 мең сум 2021 ел - 500 мең сум 2022 ел - 500 мең сум 2023 ел - 500 мең сум 2024 ел - 500 мең сум 2024 ел - 500 мең сум)

- республика бюджеты - (республика һәм федераль программаларда катнашу кысаларында. КУЭны үстерүгә грантлар). Балтач муниципаль районы бюджетыннан финанслау күләме чираттагы финанс елына карар нигезендә ел саен аныкланачак. Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.».

1.3. Кушымта нигезендә 4.1 бүлек белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны Интернет-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач районы башкарма
комитеты җитәкчесе А. Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2020 елның _17.04______
___151_____ номерлы карарына
кушымталар

**Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү**

## I. Кереш

Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү (алга таба – КУЭ) кече һәм урта бизнесны үстерү буенча дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләренең берсе булып тора. «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы (алга таба – 209-ФЗ номерлы Закон) КУЭ субъектларына озак вакытлы арендага, шул исәптән ташламалы шартларда бирү өчен дәүләт һәм муниципаль мөлкәт исемлекләрен күрсәтелгән органнар тарафыннан раслауны күздә тота.

КУЭ субъектлары арасында җитештерү һәм административ биналар, биналар, җир участоклары, шул исәптән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр, транспорт чаралары, җиһазлар кебек мөлкәт төрләренә карата мөлкәти ярдәмгә ихтыяҗ бар.

КУЭ субъектлары мөлкәти ярдәм алуның кыенлаштыра торган түбәндәге сәбәпләрне билгеләп үтә: дәүләт яки муниципаль мөлкәтне алу өчен мөрәҗәгать иткәндә документларның күплеге, мөлкәт бирү вакыты озак булу, ярдәм алу тәртибенең ачык булмавы, мөлкәт һәм аны бирү процедуралары турында мәгълүмат булмау.

КУЭ субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хуҗалык әйләнешенә җәлеп итүгә, кече һәм урта бизнесның мөлкәти базасын ныгытуга ярдәм итәчәк, шул ук вакытта аренда түләүләре керү, шулай ук киләчәктә арендага алучылар тарафыннан мөлкәтне сатып алу хисабына бюджет керемен арттырачак.

## II. КУЭ субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү максатлары һәм бурычлары

«Кече һәм урта эшкуарлык һәм индивидуаль эшкуарлык инициативасына ярдәм итү» Милли проекты паспорты 2024 елның 1 декабренә КУЭ субъектларының ташламалы шартларда бирелә торган мөлкәткә керүне объектларның, шул исәптән кулланылмый торган, нәтиҗәсез файдаланыла торган яисә билгеләнеше буенча файдаланылмый торган  объектларның гомуми санын исемлектә 66 000 объектка кадәр тулыландыру хисабына тәэмин итүне

күздә тота. 2021 ел ахырына кадәр КУЭ субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү юнәлеше буенча, исемлеккә кертелгән объектлар санының еллык үсешен һәм КУЭ субъектларына арендага бирелгән объектларның өлешен арттыруны да кертеп, максатчан күрсәткечләрне билгели торган 2017 елның 31 гыйнварындагы 147-р номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең күрсәтмәсе белән «Кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү» Максатчан моделе расланды.

Әлеге Программаның максаты - Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә регионның (муниципаль берәмлекнең) мөлкәт потенциалыннан файдалану хисабына кече һәм урта бизнес үсешен стимуллаштыру.

Әлеге Программаның бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

1. КУЭ субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлегендә (алга таба - Исемлек) Балтач муниципаль районының муниципаль мөлкәтен арттыру.

2. Исемлеккә кертелгән мөлкәт составын киңәйтү, аның сыйфатын яхшырту.

3. КУЭ субъектларына Исемлекләрдә булган шартнамәләр нигезендә озак вакытка биләүгә (файдалануга) бирелә торган мөлкәт санын арттыру.

4. Мөлкәтне арендага бирү буенча ташламалы тәртипне камилләштерү.

5. Мөлкәтне биләү (файдалану) процедураларының гадилеген һәм аңлаешлылыгын арттыру.

## III. Программаны гамәлгә ашыру башына КУЭ субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү эшенең торышы

209-ФЗ номерлы Закон кабул ителгән көннән алып, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль мөлкәте исемлегенә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм оешмаларга биләүгә һәм (яки) файдалануга бирү өчен билгеләнгән гомуми мәйданы 1989,2 кв. м булган 10 күчемсез мөлкәт объекты кертелгән.

Әлеге Программаны әзерләү датасына Балтач муниципаль районы территориясендә 620 (КУЭ субъектлары саны) теркәлгән.

## IV. КУЭ субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәткәндә Балтач муниципаль районы муниципаль мөлкәте белән идарә итү һәм аның белән эш итү принциплары һәм өстенлекләре

Балтач муниципаль районы территориясендә КУЭ субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү түбәндәге принципларда төзелә:

**мәгълүмати ачыклык (транспарантлык):** «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтларда Исемлеккә кертелгән мөлкәт турында, мөлкәти ярдәм күрсәтүне җайга сала торган хокукый актлар һәм мондый актларның

проектлары турында, КУЭ субъектлары өчен мөлкәтне үстерү буенча реклама һәм мәгълүмати кампанияләр үткәрү турында мәгълүмат урнаштыру;

мөлкәти ярдәм алуга КУЭ **субъектларының тигез мөмкинлеге:** КУЭ субъектларына мөлкәтне биләүгә һәм (яки) файдалануга бирү турындагы карарларны әзерләү, кабул итү һәм үтәү барышында конкурентлыкны саклау турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәү;

яңа ачыкланган, шулай ук файдаланылмый торган, нәтиҗәсез файдаланыла торган яки билгеләнеше буенча файдаланылмый торган **муниципаль милеккә кергән мөлкәтне**, мондый мөлкәтне куллану җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен җирле үзидарә органнарын яки муниципаль оешмаларны урнаштыру өчен кирәк булган очраклардан тыш, **Исемлеккә кертү өстенлеге.**

аларга карата КУЭ субъектларының арендалана торган муниципаль мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукы тормышка ашырылган мөлкәтне алыштыру максатларында, **ел саен Исемлекне яңа объектлар белән тулыландыру;**

**Исемлеккә кертелгән мөлкәткә ихтыяҗ:** КУЭ субъектларына озак вакытлы арендага бирелә алмый торган яисә алар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген алып бару өчен файдаланыла алмый торган мөлкәт исемлегенә кертүгә юл куймау;

Россия Федерациясе законнары һәм Балтач муниципаль районының норматив хокукый актларында каралган рөхсәт ителгән бер формада аңа тотылган чыгымнарны каплау шарты белән арендага алучы акчалары исәбеннән, муниципаль мөлкәтнең техник һәм санитар торышын яхшырту өчен **шәхси инициативадан файдалану;**

**Исемлеккә кертелгән мөлкәтне максималь күләмдә**, аны КУЭ субъектларына сатуларда аренда шартнамәсен төзү хокукына тәкъдим итү, мондый сатулар үткәрүне башлап җибәргәндә гариза принцибын куллану, шулай ук КУЭ үстерү чараларын үз эченә алган яисә Россия Федерациясенең җир законнары нигезендә каралган программаларда (ярдәмче программаларда) каралган муниципаль преференцияләр кысаларында сатулар үткәрмичә генә бирү юллары белән **аренда мөнәсәбәтләренә җәлеп итү.**

## V. КУЭ субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү өлкәсендә эшчәнлекне норматив хокукый тәэмин итү буенча чаралар

КУЭ субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтүне норматив хокукый тәэмин итү 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы нигезләмәләренә нигезләнгән. «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтүне киңәйтү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 3 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон белән (алга таба - 185-ФЗ номерлы Закон) кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, Исемлеккә муниципаль милектәге җир кишәрлекләре, шулай ук хуҗалык алып бару яисә оператив идарә итү хокукында муниципаль унитар предприятиеләргә, учреждениеләргә

беркетелгән муниципаль мөлкәт кертелергә мөмкин. Күрсәтелгән Федераль закон 2018 елның 3 июленнән КУЭ субъектлары тарафыннан арендалана торган дәүләт һәм муниципаль күчемсез мөлкәтнең базар бәясе буенча өстенлекле сатып алу хокукының гамәлдә булу вакытын чикләнмәгән нигезгә күчерде.

Балтач муниципаль районында КУЭ субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү өлкәсендә түбәндәге норматив хокукый актлар эшли:

«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы милкендә булган муниципаль мөлкәтне арендага бирү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 25 июлендәге 201нче номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Советының карары;

«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль мөлкәт Исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукыннан азат булган (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга биләүгә һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәтен, шул исәптән җир кишәрлекләрен (шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү Тәртибен һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль мөлкәт Исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукыннан азат булган (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга биләүгә һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт, шул исәптән җир кишәрлекләре (шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) Исемлеген формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару Тәртибен раслау турында» 2019 елның 17 декаберендәге 225 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советының карары;

## VI. Исемлекне тулыландыру өчен муниципаль мөлкәтне ачыклау

Исемлекне тулыландыру өчен муниципаль мөлкәтне ачыклау һәм сайлап алу Балтач муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасының координацияләнгән эшен таләп итә, моның өчен «КУЭ» Корпорациясе» АҖ ярдәмендә түбәндәге коллегиаль органнар (эшче төркемнәр) төзелә:

– муниципаль районда КУЭ субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү өлкәсендә эшче төркем.

Эшче төркем вәкаләтле органнар тарафыннан ел саен  уздырыла торган дәүләт, шулай ук муниципаль мөлкәтне, шул исәптән: казна мөлкәтен, оператив идарә хокукында һәм хуҗалык алып бару хокукында муниципаль учреждениеләргә, предприятиеләрдә (алга таба - МУ, МУП) беркетелгән

мөлкәтне, җир кишәрлекләрен, шул исәптән дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен инвентаризацияләүдә катнаша.

## VII. Муниципаль мөлкәт турында мәгълүматның һәркем файдалану мөмкинлеген арттыру, аны исәпкә алуны камилләштерү

2018 елның 5 апрелендә конкурентлыкны үстерү мәсьәләсе буенча (2018 елның 15 маендагы Пр-817ГС номерлы йөкләмәләр исемлеге) Россия Федерациясе Дәүләт Советы утырышында бирелгән Россия Федерациясе Президенты күрсәтмәләре буенча, «Интернет» челтәрендәге Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең рәсми сайтларында Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милкендә, муниципаль милектә булган объектлар, шул исәптән объектларның исемнәре, аларның урнашу урыны, характеристикасы һәм максатчан билгеләнеше, өченче затлар хокукларыннан файдалануны һәм йөкләнешне чикләү турында мәгълүмат урнаштырылырга тиеш. Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль мөлкәт турындагы мәгълүматның һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итү максатларында «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтларда урнаштыру өчен белешмәләр составын, муниципаль мөлкәт реестрына кертелгән мөлкәт турындагы мәгълүматны урнаштыру вакытларын һәм актуальләштерү тәртибен билгеләүче хокукый актлар эшләнәчәк һәм расланачак.

Муниципаль мөлкәт объектлары турында белешмәләр «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларда күчемсез милек объектына хокукларны чикләүне (йөкләнешне) теркәү яки күрсәтелгән объектка милек хокукын туктату датасыннан җиде көн эчендә актуальләштерелергә тиеш.

## VIII. Исемлекне яңа мөлкәт белән тулыландыру, кирәксез мөлкәтне төшереп калдыру

Исемлекне тулыландыру турындагы тәкъдимне формалаштыру өчен яраклы булган кирәксез мөлкәтне яки билгеләнеше буенча файдаланылмый торган мөлкәтне ачыклау барышында, Эшче төркем мондый тәкъдимнәрне җыю һәм карауны контрольдә тотуны тәэмин итәчәк.

Югарыда күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыру белән бер үк вакытта Эшче төркем КУЭ субъектлары тарафыннан ихтыяҗ булмаган мөлкәтнең Исемлектә булу-булмавын тикшерә. Әгәр  Исемлеккә кертелгәннән соң ике ел дәвамында объект буенча КУЭ субъектыннан бер генә гариза да алынмаган һәм бу чорда аренда шартнамәсен төзү хокукына игълан ителгән сатулар ике тапкырдан артык узмаган дип танылган очракта, мондый мөлкәтне Исемлектән төшереп калдыру турында тәкъдимнәр әзерләнергә мөмкин.

Программа гамәлдә булган чорда Исемлектәге мөлкәт санын 40% ка 14 объектка кадәр арттыру планлаштырыла.

## IX. Исемлеккә кертелгән муниципаль мөлкәтне бирү эшен камилләштерү

Исемлеккә кертелгән муниципаль мөлкәтне бирү буенча эшнең максаты - мөлкәтне Исемлеккә кертү датасыннан соң бер елдан да соңга калмыйча максималь мөмкин булган күләмдә аренда шартнамәләре төзү. Әлеге максатка ирешү өчен түбәндәге адымнар тормышка ашырылачак:

- потенциаль арендага алучыларга мөлкәт турында мәгълүмат, шул исәптән фотографияләр, техник документлар, шулай ук реклама характерындагы материаллар бирү;
- муниципаль массакүләм мәгълүмат чараларында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтларда КУЭ субъектлары өчен мөлкәт буенча ел саен мәгълүмати кампанияләр үткәрү;
- мөлкәтне арендага бирү буенча сатулар (торги) үткәрү турында карар кабул иткәндә гариза принцибын куллану;
- КУЭ субъектларына сатуларда һәм сатулар уздырмыйча гына мөлкәтне бирү процедураларында катнашу буенча методик материаллар эшләү һәм бирү.

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Балтач муниципаль районының рәсми сайтында «КУЭ субъектларына мөлкәти ярдәм» юнәлеше буенча бүлек төзеләчәк. КУЭ субъектларына мөлкәтне арендага бирү буенча вәкаләтле органнарның эшчәнлеге ел дәвамында административ регламент белән җайга салыначак.

## X. КУЭ субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү буенча максатчан күрсәткечләр

| т/б № | Максатчан күрсәткеч | Төп (база) төшенчә | | Чор, ел | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 1 | Ел саен дәүләт мөлкәте исемлекләрендә һәм Россия Федерациясе субъектларында муниципаль мөлкәт исемлекләрендә мөлкәт объектлары саны 10% ка артуы (берәмлек) | 4 | 6 | 10 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
| 1.1. Казна муниципаль мөлкәт объектлары | | | | | | | | | |
| 1.1.1. | Җир кишәрлекләре (төрле билгеләнештәге) | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 1.1.2 | Авыл хуҗалыгы билгеләнешендә- | - | - | - | - | - | - | - | - |

| т/б № | Максатчан күрсәткеч | Төп (база) төшенчә | | Чор, ел | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| | ге җир кишәрлекләре | | | | | | | | |
| 1.1.3 | Күчемсез мөлкәтнең башка объектлары | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 1.1.4 | Күчемле мөлкәт | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 1.2. Дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләренә хуҗалык алып бару хокукында дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә оператив идарә хокукында беркетелгән мөлкәт | | | | | | | | | |
| 1.2.1 | Күчемсез мөлкәт | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 1.2.2 | Күчемле мөлкәт | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 2. | Исемлектә мөлкәтнең гомуми санына карата аренда шартнамәләре өлеше (процентларда) | - | - | - | 10 | 9 | 8 | 15 | 14 |

Әлеге бүлектә билгеләнгән максатчан күрсәткечләргә ирешүне контрольдә тоту дәрәҗәсе: Балтач муниципаль районы башлыгы.»;

Программаның 2 нче кушымтасын түбәндәге эчтәлектәге 6 нчы юл белән тулыландырырга:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 6. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына биләүгә һәм (яки) файдалануга һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль мөлкәте Исемлегенә кертелгән мөлкәтне арендага бирү; Исемлеккә кертелгән өчен | Балтач муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы | Даими | Кирәк түгел |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | аренда түләве буенча ташламаларны куллану (кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен аренда түләвенең ташламалы ставкаларын куллануны да кертеп). | | | |